РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН
СОВЕТ ИЗМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
, Республика Татарстан, Сабинский
район,
с.Измя, ул. Школьная, 9
тел. (84362) 49-1-32, 49-1-22

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЭЗМӘ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422052, Татарстан Республикасы,
Саба районы,
Эзмә авылы, Мәктәп урамы, 9 йорт
тел. (84362) 49-1-32, 49-1-22

e-mail: Izm.sab@tatar.ru

**КАРАР** 27.07.2023г.

**РЕШЕНИЕ** № 12

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Измя авыл җирлеге Советының 08.11.2021 елгы № 25 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Измя авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Измя авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Измя авыл җирлеге Советының «Саба муниципаль районы Измя авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» 08.11.2021 елгы № 25 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Измя авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәгә (текст буенча алга таба – нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2 пунктның беренче абзацын «Энергетика нәтиҗәлелеге» сүзләреннән соң, «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында законнар» сүзләр белән тулыландырырга;

1.2. 1.2 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 12 нче пункт белән тулыландырырга:

«12) йорт эчендәге һәм (яки) фатир эчендәге газ җиһазларын куркынычсыз эксплуатацияләүгә һәм техник хезмәт күрсәтүгә таләпләр, шулай ук күп фатирлы йортта гомуми милеккә караган вентиляция һәм төтен каналларын тотуга таләпләр.»;

1.3. 1.6 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6. Муниципаль торак контроле объектлары булып:

1) контрольдә тотылган затларның эшчәнлеге, гамәлләре (гамәлсезлеге), алар кысаларында мәҗбүри таләпләр үтәлергә тиеш, шул исәптән әлеге Нигезләмәнең 1.2

пунктының 1–12 пунктчаларында күрсәтелгән эшчәнлек алып баручы контрольдә тотылган затларга карата куелган гамәлләр (гамәлсезлеге);

2) контрольдә тотылган затларның эшчәнлеге нәтиҗәләре, шул исәптән әлеге Нигезләмәнең 1.2 пунктындагы 1–12 пунктчаларында күрсәтелгән мәҗбүри таләпләр куелган эшләнмә (товарлар), эшләр һәм хезмәтләр;

3) муниципаль торак фондының торак биналары, муниципаль торак фондының торак биналары булган күпфатирлы йортлардагы гомуми милек һәм әлеге Нигезләмәнең 1.2 пунктындагы 1–12 пунктларында күрсәтелгән мәҗбүри таләпләр куела торган башка объектлар.»;

1.4. 1.7. пункттагы өченче абзацны гамәлдән чыгарырга;

1.5. 5. “Судка кадәрге шикаять” бүлеген гамәлдән чыгарырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мағълуматлар турындагы расми порталында мағълумати-телекоммуникацион “Интернет” челтәренда http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Измя авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/izma адресы буенча урнаштырырга.

Измя авыл җирлеге башлыгы: Р.Г.Ахметов.